ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 621-60/т-2025

«Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә 2026 елга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар билгеләү турында

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә салу чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы, «Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәт күрсәтүләренә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтен күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәт күрсәтүләренә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтен күрсәтүләргә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) яисә аларның иң чик дәрәҗәсен билгеләү (үзгәртү) мәсьәләләрен, шулай ук аларны билгеләү (үзгәртү) өчен күрсәтелә торган документлар исемлекләрен карау тәртибен раслау турында» 2009 елның 24 июнендәге 135-Т/1 номерлы боерыгы, Федераль тарифлар хезмәтенең 2014 елның 31 октябрендәге 238-т/2 номерлы боерыгы белән расланган Аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәт күрсәтүләренә җыемнарны һәм тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу мәсьәләсе буенча методик күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, №468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 18.12.2025 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә «Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик дәрәҗә максималь тарифлар һәм җыемнар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2025 № 621-60/т-2025
карарына кушымта

«Бөгелмә» аэропорты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан аэропортта күрсәтелә торган хезмәтләргә 2026 елга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар һәм җыемнар

| Т/с | Җыем һәм тариф исеме | Үлч. бер. | Җыем күләме, тариф (ӨХС исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Һава судноларының очып китүен, утыруын һәм туктап торуын тәэмин иткән өчен җыем | сум/т мвм | 920,0 |
| 2. | Транспорт иминлеген тәэмин иткән өчен җыем | сум/т мвм | 782,0 |
| 3. | Эчке линияләрдә аэровокзал (терминал) биргән өчен җыем | сум/пасс. | 194,0 |
| 4. | Эчке һава линияләрендә пассажирларга хезмәт күрсәтү өчен тариф | сум/пасс. | 451,0 |
| 5. | Һава судноларына авиация ягулыгы салуны тәэмин иткән өчен тариф | сум/т | 3 706,0 |
| 6. | Авиация ягулыгын саклау өчен тариф | сум/т | 2 388,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге